МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 89/о

П Р И К А З　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

« 24 » 05 2021

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә капиталь төзелеш объектын төзү планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору очрагында, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп коруны Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылса, капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә капиталь төзелеш объектын төзү планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору очрагында, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп коруны Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылса, капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Юридик бүлеккә, дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Территорияләрне планлаштыру һәм төзү бүлегенә әлеге боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң җиде эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объекты төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 8 апрелендәге 56/о номерлы;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 8 апрелендәге 56/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 19 октябрендәге 161/о номерлы.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «24» 05.2021 № 89/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә капиталь төзелеш объектын төзү планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору очрагында, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп коруны Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылса, капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының әлеге Административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә капиталь төзелеш объектын төзү планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору очрагында, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп коруны Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылса, капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик һәм физик затлар, шәхси эшкуарлар.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышаныч кәгазе яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче – Министрлыкның архитектура һәм шәһәр төзү идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзеп тутыру бүлеге (алга таба – вәкаләтле бүлекчә).

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10.

Вәкаләтле бүлекчә урнашкан урын: Казан шәһәре, Кремль урамы, 13, 3 нче кат,

302 кабинет.

Министрлыкның эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

«Кремль» тукталышына кадәр җәмәгать транспортында килү өчен: 98 нче автобус; «Университет» тукталышына кадәр: 8, 10, 10а, 30, 35, 54, 63, 91, 99а санлы автобуслар; 7, 17, 20, 21 санлы троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Вәкаләтле бүлекчәнең белешмә телефоннары: (843) 231-15-16, (843) 231-14-28, (843) 231-14-64.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.minstroy.tatar.ru, электрон почта адресы: msagkh@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/) (алга таба – Республика порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә;

5) «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенә һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең (алга таба – күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны) ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта (шәхсән яисә телефон буенча).

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат вәкаләтле бүлекчә белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Хезмәтләр күрсәтү реестры) һәм Республика порталында урнаштырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Административ регламент (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

Мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла

торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Административ регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) булган дәүләт хезмәте күрсәтүтурындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.3.6. Бердәм порталда, Республика порталында Хезмәтләр күрсәтү реестрында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, Хезмәтләр күрсәтү реестрында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып тора торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәш-

леген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаларның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Административ регламентка карата 1 нче, 2 нче кушымталарда китерелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү, әгәр капиталь төзелеш объектын Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә төзү планлаштырылса, һәм Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта, төбәк яки муниципальара билгеләнештәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп коруны Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылса | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы | Министрлык турындагы нигезләмәнең 3 бүлеге |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү | Төзелешкә рөхсәт; | РФ Шәһәр төзелеше |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәсенә тасвирлама | төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү (шул исәптән рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайту зарурлыгына бәйле рәвештә дә)<br>төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү;<br>төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында белдерү. | кодексының 51 статьясы |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | 1. Төзелешкә рөхсәт бирү яки бирүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру вакыты төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза Министрлыкта теркәлгәннән соң биш эш көне тәшкил итә.<br>2. Төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү яки төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру срогы мөрәҗәгать итүчедән яки төзүче оешмадан җир кишәрлекләренә булган хокукларның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының үзләренә күчүе турында, җир кишәрлеге булдыру турында белдерү теркәлгән яки, төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озынайту зарурлыгына бәйле рәвештә, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында төзүче оешмадан гариза теркәлгән көннән башлап биш эш көне тәшкил итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>3. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта төзелешкә рөхсәт бирү турында (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында) гаризаны (алга таба – гариза) һәм теркәлгән документларны Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә. Төзелешкә рөхсәт бирү яисә бирүдән баш тарту (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү яисә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) процедурасын гамәлгә ашыру вакытына гаризаның күпфункцияле үзәктә булган вакыты һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә Министрлыктан күпфункцияле үзәккә тапшыру вакыты кертелми.<br>Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны тапшыру мөрәҗәгать итүче килгән көнне, төзелешкә рөхсәт алу турында төзелешкә бирелгән рөхсәтләр журналында имзалатып гамәлгә ашырыла.<br>Гаризада бу хакта күрсәтелгән булса, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында мөрәҗәгать итүчегә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | җибәрү төзелешкә рөхсәтне теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул (почта буенча, электрон почта адресына) белән рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы белдерүне тапшыру (җибәрү) төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турындагы хат теркәлгән көннән башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 2.5.1. Төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза (әлеге регламентка 1 нче кушымта);<br>Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза (әлеге регламентка 2 нче кушымта);<br>җир кишәрлекләренә хокукларның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының башка затка күчүе турында һәм җир кишәрлеге оештыру турында белдерү (алга таба – хокукның башка затка күчүе турында белдерү).<br>Хокукның башка затка күчүе турындагы гариза яки белдерү мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән, Министрлык адресына почта юлламасы итеп, күпфункцияле үзәк аша, Республика порталы ярдәмендә тапшырыла.<br>Гариза яисә хокук күчүе турында белдерү кулдан, машина ысулы белән яисә компьютер ярдәмендә тутырыла һәм, булган очракта, мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныклана. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы, «Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһер мәҗбүрилеген гамәлдән чыгару өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон |
| | 2.5.2. Төзелешкә рөхсәт бирү, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза әлеге Административ регламентка 1 нче, 2 нче кушымталарда китерелгән үрнәкләр буенча төзелә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы |
| | 2.5.3. Хокукның башка затка күчүе турындагы белдерүдә реквизитлар күрсәтелергә тиеш:<br>1) мондый җир кишәрлекләренә хокуклар күчкән очракта, җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документларныкы;<br>2) җир кишәрлеге оештыру турында карарныкы, әгәр җир законнарына ярашлы рәвештә җир кишәрлеге булдыру турында карарны дәүләт хакимияте башкарма органы яисә җирле үзидарә органы кабул итсә, түбәндәге очракларда:<br>үзләренә яки берәрсенә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге оештырылган очракта;<br>үзләренә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | таратып бүлү яки җир кишәрлекләре арасыннан аерып чыгару юлы белән җир кишәрлекләре булдырылган очракта;<br>3) үзләренә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, таратып бүлү яки җир кишәрлекләре арасыннан аерып чыгару юлы белән җир кишәрлекләре булдырылган очракта, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору планлаштырыла торган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы буенча;<br>4) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^9$ өлешендә каралган очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының бирелүе турындагы карарныкы һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы карарныкы.<br>Хокук көчүе турындагы белдерүгә мөрәҗәгать итүче югарыда аталган документларның күчермәләрен теркәргә хокуклы | |
| | 2.5.4. Төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәгеләр теркәлә:<br>1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләнүе турында килешү, гавами сервитут билгеләнүе турында карар, шулай ук, РФ Шәһәр төзелеше кодексының $57^3$ статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруга нигез булган һәм җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашкан схема, әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $7^3$ өлешендә башкача билгеләнмәсә;<br>2) Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), бюджетка карамаган дәүләт фондының идарә органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән килешү булган очракта, – әлеге килешү, үзе белән әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукын билгели торган документлар;<br>3) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза тапшырылган көнгә кадәр кимендә өч ел алдан алынган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектының һәм территорияне ызанлау проектының реквизитлары (линияле объект төзелеше, аны үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $7\text{-}7^2$ өлеше,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәт һәм эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары (алга таба – 729 номерлы ТР МК карары) |

| | | |
|---|---|---|
| | документларын әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объект төзелеше өчен рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектының реквизитлары;<br>4) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 15 өлеше нигезендә расланган проект документларында булган, түбәндәге материаллар:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген оештыруны планлаштыру схемасы, ә линияле объектларга карата проект документлары әзерләнгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган аерып чыгару полосасы проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документлары таләп ителми торган очраклардан тыш);<br>в) архитектура һәм корылма чишелешләрен, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чишелешләрне һәм чараларны үз эченә алган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эш, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектлар, торак фонды объектларына карата проект документлары әзерләнгән очракта);<br>г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (башка капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү зарурлыгы булган очракта, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);<br>5) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору өчен нигез булган проект документларының уңай экспертиза бәяләмәсе (проект документларының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе өлешендә), шул исәптән, әгәр әлеге проект документларынд, линияле объектларны да (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $12^1$ өлешендә каралган очракта, аерым төзелеш этапларына карата) кертеп, башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки үзгәртеп кору да каралган булса, әгәр мондый проект документлары РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә | |

| | | |
|---|---|---|
| | экспертизага тиешле булса, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^{4}$ өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе;<br>6) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^{8}$ өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, проект документларына кертелә торган, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлардан тупланган әгъзаларга нигезләнгән үзкөйләнешле оешма әгъзасы булып торган зат тарафыннан тапшырылган һәм әлеге зат тарафыннан РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектлавын оештыру буенча белгеч буларак җәлеп ителгән зат тарафыннан расланган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^{8}$ өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүенә раслама;<br>7) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^{9}$ өлеше нигезендә экспертлар белән бергә эшләү барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, проект документларына кертелә торган, башкарма хакимият органы яки проект документларына экспертиза уздырган оешма тарафыннан тапшырылган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^{9}$ өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүенә раслама;<br>8) рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәт (әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясына ярашлы рәвештә төзүче оешмага андый рөхсәт бирелгән булса);<br>9) капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләреннән ризалык, – мондый объект үзгәртеп корылган очракта;<br>10) дәүләт (муниципаль) мөлкәтендәге, хокук иясе булып дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яисә автоном учреждениесе торган капиталь төзелеш объектында үзгәртеп кору эшләре әлеге органнарга карата гамәлгә куючы функцияләрен яисә мөлкәтнең милекчелек хокукы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы, бюджетка карамаган дәүләт фондының идарә органы яисә | |

| | | |
|---|---|---|
| | җирле үзидарә органы) булып торган дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан уздырылган очракта, – мондый үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру турында, шул исәптән үзгәртеп кору барышында әлеге объектка китерелгән зыянны каплау шартлары һәм тәртибе билгеләнә торган, килешү;<br>11) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза буенча уңай бәяләмә бирүче юридик затның аккредитация турында таныклык күчермәсе, әгәр проект документларына карата дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе тапшырылган булса;<br>12) мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздырылганда мондый объектның ышанычлы һәм куркынычсыз булуына кагылышлы конструктив һәм башка сыйфатламалары кузгатылса;<br>13) урнаштырылуына бәйле рәвештә Россия Федерациясе законнары нигезендә территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объекты төзелгән яки, нәтиҗәдә үзгәртеп корылачак объектка карата территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләренергә яки элегрәк билгеләнгән территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона үзгәртелергә тиешле капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта, территориядән файдалануда махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе;<br>җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору планлаштырылган очракта, территорияне үстерү турында килешү күчермәсе (территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырылган яки мондый карар РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш).<br>Төзелешкә рөхсәт алу өчен кирәкле документлар бер нөсхәдә (төп нөсхәсе яисә күчермәсе) яисә ике нөсхәдә тапшырыла, аның берсе – төп нөсхә, икенчесе мөрәҗәгать итүче яисә төзүче оешма тарафыннан таныкланган күчермә булырга тиеш. Документлар ике нөсхәдә тапшырылган очракта, тикшерүдән соң төп нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Төзелешкә рөхсәт алу өчен кирәкле документлар, техник мөмкинлек булган очракта, фәкать электрон формада гына тапшырыла:<br>әгәр капиталь төзелеш объектының проект документларына экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $12^{1}$ өлешендә каралган очракта, аерым төзелеш этапларына карата), РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^{4}$ өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе электрон формада тапшырылган булса;<br>әгәр капиталь төзелеш объектына проект документлары һәм (яисә) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле башка документлар электрон формада тапшырылган булса. | |
| | 2.5.5. Төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту зарурлыгына бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар таләп ителә:<br>1) төзелеш вакытлары өлешендә төзәтмәләр кертелгән капиталь төзелеш объекты төзелешен оештыру проекты;<br>2) төзүче оешманың капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләр башлануы турында белдерү күчермәсе, аны алу турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тамгасы белән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:<br>1) Министрлыкка шәхсән яисә почта аша кәгазьдә һәм «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;<br>2) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә яки 63-ФЗ номерлы Федераль | |

| | | |
|---|---|---|
| | закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә.<br>Гаризаны тапшырган вакытта мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктән гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән язу бирелә.<br>3) Республика порталы аша электрон формада.<br>Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.<br>Гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.<br>Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.<br>Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.<br>Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон документ үрнәкләрен яки электрон формадагы документларны тапшыралар. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, | Әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктының 1-8, 11, 13 һәм 14 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) Министрлык тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына.<br>Әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктының 1, 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы белешмәләр) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында яисә бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестрында юк икән, мөрәҗәгать итүче (төзүче оешма) тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7-$7^2$ өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм аларны тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:<br>гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (танылканмаган) документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).<br>Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда урнаштырылган, хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту рөхсәт ителми. | «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләрнең (алга таба – Таләпләр) 7 пункты |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>1. Төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре:<br>1) әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктында каралган документларның булмавы;<br>2) линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, тапшырылган документларның территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документлары таләп ителми торган очраклардан тыш) таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яки) Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә һәм төзелешкә рөхсәт бирү датасына гамәлдә булган рөхсәтле төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 11 өлеше, 13 өлеше, $21^{15}$ өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | параметрларыннан тайпылуга бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>3) территорияне комплекслы үстерү турындагы килешү нигезендә расланган территорияне планлаштыру документларының булмавы (территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырылган яки мондый карар РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш).<br>2. Төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту зарурлыгына бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту нигезләре:<br>1) хокукның башка затка күчүе турындагы белдерүдә күрсәтелгән белешмәләрнең төгәл булмавы;<br>2) планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^7$ өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруның шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве. Бу вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{10}$ өлешендә күрсәтелгән белдерү җибәреләсе көнгә кадәр кимендә өч ел алдан бирелгән булырга тиеш;<br>3) Министрлыкта дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге яки муниципаль җир контроле кысаларында төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуга бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны тапшыру көненә төзелеш, үзгәртеп кору буенча башланган эшләрнең булмау фактын ачыклау турында мәгълүмат яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 5 өлешендәге таләпләр нигезендә мондый белдерүне җибәрү мәҗбүри булып торса, әлеге эшләрне башлап җибәрү турында белдерү булмавы турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органыннан мәгълүмат булуы, әгәр төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуга бәйле булса. Бу очракта Министрлык, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан да | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдаланып, тиешле дәүләт хакимияте органыннан яки җирле үзидарә органыннан шундый мәгълүматны соратып ала;<br>4) төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга ун эш көненнән азрак вакыт калгач төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озынайтуга бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза тапшырылуы.<br>3. Төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту нигезләре:<br>1) хокук күчүе турындагы белдерүдә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{10}$ өлешендәге 1-4 пунктларында каралган документларның реквизитлары булмавы, яисә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{13}$ өлешендә күрсәтелгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документның булмавы; яки әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктында каралган документларның булмавы;<br>2) хокукның башка затка күчүе турындагы белдерүдә күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавы;<br>3) планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{7}$ өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруның шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве. Бу вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{10}$ өлешендә күрсәтелгән белдерү җибәреләсе көнгә кадәр кимендә өч ел алдан бирелгән булырга тиеш;<br>4) планлаштырылган капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{7}$ өлешендә каралган очракта, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына гамәлдә булган чикләмәләргә туры килмәве;<br>5) капиталь төзелеш объектын урнаштыру планының рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаның төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга ун эш көненнән азрак вакыт калгач тапшырылуы.<br>Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту рөхсәт ителми. | Таләпләрнең 7 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү түләүсез нигездә башкарыла | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтүенең максималь вакыты унбиш минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Аерым категория гражданнар өчен чират билгеләнмәгән | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә | Рәсми мөрәҗәгать (гариза) һәм документлар Министрлыкка алынган көнне. | |

| | | |
|---|---|---|
| катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.<br>Гаризаны һәм теркәлә торган документларны күпфункцияле үзәккә тапшырган очракта, гариза килгән көнендә вазыйфаи күрсәтмә нигезендә гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыра торган күпфункцияле үзәк хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) тарафыннан теркәлә.<br>Гаризаны һәм теркәлә торган документларны Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә.<br>Күпфункцияле үзәк аша килгән гариза һәм теркәлә торган документлар Министрлыкта алынган көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:<br>1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;<br>5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру; | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;<br>7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;<br>9) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм әлеге пунктның 3-6 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керեп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>инвалидларга, биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, башка затлар белән тигез дәрәҗәдә аларга хезмәтләр алуга комачау итүче башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы; | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан |

| | | |
|---|---|---|
| һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтүдән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә бер мәртәбәдән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта, документларны кабул итү һәм бирү күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны һәм аңа теркәлгән документларның гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә Министрлыкка тапшырылуы тәэмин ителә.<br>Гаризада мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә алуы күрсәтелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәктә бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүче белән эшләү тәртибе КФҮ эш регламентында җайга салына.<br>Экстерриториаль принцип буенча яки комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 2.4 пункты |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану турында гаризаны «Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталы» мәгълүмат системасы аша Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталының Интернет-кабул итү системасыннан электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге бар.<br>Техник мөмкинлек булган очракта, документлар «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмат системасы аша электрон формада җибәрелергә мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияне Республика порталы аша алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте түбәндәге очракларда электрон формада күрсәтелә: | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы,<br>729 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| | - әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясенә экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә (электрон цифрлы имза белән таныклап) электрон формада тапшырылган булса;<br>- әгәр капиталь төзелеш объектына проект документлары һәм (яисә) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле башка документлар электрон формада тапшырылган булса.<br>Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ яки аның ИАБС системасы аша алынган, стандарт исәпкә алу язуыннан түбәнрәк булмаган реквизитлары (электрон форма тутырылган очракта).<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзалана.<br>Республика порталы аша алынган гаризаны теркәү «Татарстан Республикасы Дәүләт мәгълүмат үзәге» мәгълүмат системасыннан эчке файдаланучылары өчен электрон рәвештә дәүләт, муниципаль һәм социаль-әһәмиятле хезмәтләр күрсәтү модулендә гамәлгә ашырыла.<br>Гаризаны Республика порталы аша тапшырган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына электрон формада җибәрелә, мөрәҗәгать итүченең башкаручы зат белән турыдан-туры хезмәттәшлеге таләп ителми. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

3.1.1.1 гаризаны шәхсән кәгазь документ формасында тапшырган очракта:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризаларны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү;

4) ведомствоара электрон хезмәттәшлекләр;

5) төзелешкә рөхсәт бирү турында (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында) карар әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.1.1.2 гаризаны Республика порталы аша электрон формалы гариза итеп тапшырган очракта:

1) Республика порталында мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның электрон формасын тутыру;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына нәтиҗәне җибәрү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче вәкаләтле бүлекчәгә язмача формада, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы (http://www.minstroy.tatar.ru) аша электрон хәбәр итү формасында яисә вазыйфаи затка шәхсән мөрәҗәгать итү формасында дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтле бүлекчә белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларны рәсмиләштерү буенча һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен башка мәсьәләләрдә консультацияләү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Төзелешкә рөхсәт бирү һәм төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче гаризаны шәхсән үзе, ышанычлы заты аша, почта, электрон почта буенча, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшыра ала.

Гаризаны Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизацияләнә;

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

Документларны тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук, әлеге Административ регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә, тапшырылмый торган документларның да исемлеге төзелә.

Тапшырылмый торган документлар исемлегендә алар белән эш итә торган органнарның атамалары, теркәлү номерлары, теркәлү даталары, аерым очракларда, тиешле рәсми мөрәҗәгатьләрне тапшыру өчен кирәкле, аларда булган белешмәләр күрсәтелә.

Гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны, шулай ук хокук күчүе турындагы белдерүне мөрәҗәгать итүче, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда һәм әлеге Административ регламентта билдерелгән таләпләрне үтәп, электрон формада тапшырырга хокуклы.

Документлар электрон формада тапшырылган очракта, гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, шулай ук хокук көчүе турындагы белдерү гаризага кул куйган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмат системасы, Республика порталы аша җибәрелергә мөмкин. Электрон формада алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Министрлыкның төбәкара багланышлар һәм документлар үтәлешен тикшереп тору бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, шулай ук хокукның башка затка күчүе турындагы белдерүне Министрлыкның эшчәнлек күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә терки һәм карау өчен вәкаләтле бүлекчәгә юллый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формалы гариза вәкаләтле бүлекчәгә электрон почта буенча яисә Интернет-кабул итү системасы аша җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Вәкаләтле бүлекчәнең дәүләт хезмәте күрсәтү бурычы йөкләнгән вазыйфаи затлары (алга таба – Бүлек белгечләре) Төзелешкә рөхсәтләр бирү (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү, хокук күчүе турындагы белдерүләрне теркәү) турындагы гаризаларны, хокук күчүе турындагы белдерүләрне теркәү журналын (алга таба – Журнал) алып бара.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы);

мөрәҗәгать итүченең атамасы;

документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары;

объектның аталышы һәм килгән документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны;

төзелешкә рөхсәт әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәтне (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тартуны) тапшыру датасы яисә почтадан юллау датасы;

төзелешкә рөхсәт (документларны теркәп, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы;

төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү (төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында белдерү тапшыру датасы яисә почта аша юллау датасы;

искәрмә.

Журнал кулдан язып һәм электрон формаларда, әлеге Административ регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы рәвештә алып барыла.

Бүлек белгечләре килгән гариза турындагы белешмәләрне Журналга кертә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза белән документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Журналдагы язу.

3.4. Гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү.

3.4.1. Бүлек белгечләре тапшырылган документлар җыелмасын әлеге Административ регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәве буенча тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар килгән гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның комплектлылыгын билгеләү.

3.4.2. Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хәбәр итә һәм белдерүне 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Министрлыкның вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Республика порталындагы шәхси кабинетка юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач дүрт эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.5. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.5.1. Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документлар килгәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Бүлек белгечләре дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнарга, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарга, дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган органнарга, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнаша торган башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә ярашлы рәвештә белешмәләр алу өчен ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза белән документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек эшендә катнаша торган органнар әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны билгеләнгән чорда бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы $7^1$ өлешендә билгеләнгән вакыт эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар яки мәгълүматның булмавы турында белдерү.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Бүлек белгечләре проект документларының капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен, яисә, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документлары таләп ителмәгән очраклардан тыш) проекты таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм Россия Федерациясенең җир законнарында һәм башка законнарында билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирү көненә гамәлдә булган чикләмәләргә ярашлы рәвештә капиталь төзелеш объектын урнаштыруның мөмкин булу-булмавын тикшерә. Затка рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәт ителгән очракта, проект документларына яисә җир кишәрлеген планда оештыру схемасына рөхсәтле төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килүе-килмәве буенча тикшерү уздырыла.

Тапшырылган документлар түбәндәгеләргә туры килү-килмәве буенча тикшерелә:

1) җир кишәрлегенең шәһәр төзү планында билгеләнгән, түбәндәгеләрне билгели торган параметрларына:

а) җир кишәрлегенең чикләре;

б) гавами сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләре;

в) алардан читтә биналар, төзелмәләр, корылмалар төзелеше башланып киткән биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны мөмкин булганча урнаштыру урыннарын билгеләү максатларында җир кишәрлеге чикләреннән минималь чигенүләр;

г) җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану турында мәгълүмат;

д) күрсәтелгән җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектының билгеләнешенә, параметрларына һәм урнаштырылуына карата таләпләр;

е) җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары, мәдәни мирас объектлары турында мәгълүмат;

ж) капиталь төзелеш объектларын инженер-техника ягыннан тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның техник шартлары турында мәгълүмат;

з) дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен капиталь төзелеш объектларын планлаштырылганча урнаштыру зоналары чикләре;

2) территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Административ регламентның 3.5.1 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән проект документлары.

3.6.2. Тапшырылган документлар территорияне планлаштыру проекты һәм

территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документлары таләп ителмәгән очраклардан тыш) таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яки) Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирелгән көнгә гамәлдә булган чикләмәләргә, рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәгән очракта һәм (яки) төзелешкә рөхсәт бирүдән, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Бүлек белгечләре төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында белдерү әзерли һәм, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының имзасы белән, мөрәҗәгать итүченең (аның вәкаләтле вәкиленең) адресына юллый.

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында белдерү электрон документ рәвешендә яисә кәгазьдә әзерләнә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турындагы белдерүне, әгәр гаризада бу хакта күрсәтелгән булса, электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат.

3.6.3. Төзелешкә рөхсәт бирү өчен җаваплы Бүлек белгечләре, тапшырылган документлар территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документлары таләп ителмәгән очраклардан тыш) таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яки) Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирелгән көнгә гамәлдә булган чикләмәләргә, рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап биргән очракта, шулай ук капиталь төзелеш объектын урнаштыруның җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану һәм Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирелгән көндә гамәлдә булган чикләмәләргә, территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелеш яки үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә ярашлы нигездә мөмкин булуы очрагында:

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр

номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелешкә рөхсәт, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүгә рөхсәт әзерли. Төзелешкә рөхсәт кәгазьдә һәм электрон документ формасында әзерләнә. Төзелешкә рөхсәт кәгазьдә ике нөсхәдә, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының имзасы белән әзерләнә, аларның берсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (гаризада күрсәтелгән очракта), икенчесе Министрлык архивында саклана. Төзелешкә рөхсәт әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Төзелешкә тапшырылган рөхсәтләр реестрында (алга таба – Реестр) аерым тәртип номеры белән исәпкә алына;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә), гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, яки күпфункцияле үзәктә, әгәр гаризада мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә ала, дип күрсәтелгән булса, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр ителә, шулай ук рәсмиләштерелгән рөхсәтне (төзелешкә бирелгән рөхсәткә кертелгән үзгәрешләрне) тапшыру көне һәм вакыты турында җиткерелә;

төзелешкә рөхсәт бирү (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү) турындагы карар Журналда теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар документларның законнардагы таләпләргә ярашлы булу-булмавын тикшерү тәмамланган көннән соң (әлеге Административ регламентның 3.6.1 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң) бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү), дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе хакында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) белдерү.

3.6.4. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) төзелешкә рәсмиләштерелгән рөхсәтне (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүне) төзелешкә рөхсәт алу турында төзелешкә тапшырылган рөхсәтләр журналында кул куйдыртып тапшыра.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, гаризада күрсәтелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Министрлыкның вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килеп җиткән көндә яки, әгәр мондый рөхсәт электрон документ формасында җибәрелә икән, төзелешкә рөхсәтне теркәгән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә бирелгән рөхсәт (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү).

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата булуы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкаләтле бүлекчәгә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Административ регламентка 5 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан Министрлыкка шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) җибәрелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә терки һәм аларны вәкаләтле бүлекчәгә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Административ регламентның 3.6.3 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүче адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Техник хатасы булган документ мөрәҗәгать итүчегә электрон формада бирелгән булса, Бүлек белгече төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып тапшыра яисә, бу хакта гаризада күрсәтелгән булса, электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы тикшереп тору Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге

Административ регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедуралар үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Административ регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүенә.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләр бозылуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

